


Мин, Хамитова Нәзилә Айратовна, 1996 елның 31 мартында Татарстан Республикасы Биектау районы Яңавыл авылында тудым. Хәзерге вакытта Айбаш гомуми урта белем бирү мәктәбенең 9 сыйныфында белем алам. ”5” һәм “4” билгеләренә өлгерәм. Районыбызда узган төрле чараларда: иҗади бәйгеләрдә, олимпиадаларда мәктәбем һәм үзем өчен катнашып барырга тырышам. Татар теле һәм рус теле олимпиадасында икенче урын алдым. Мәктәбебездә узган республика фестивалендә тикшеренү эшем шулай ук икенче урынга лаек булды. Мин җырга-моңга гашыйк, мәктәптә һәм үзебезнең авыл клубында узган концертларның берсендә дә катнашмыйча калмыйм. Минем хыялларым бик зурдан, киләчәктә җырчы булырга телим. Ә инде укудан буш вакытларымда чигү белән шөгыльләнәм, күп кенә кулъяулыклар, картиналар чигәм. Җиңүнең 65 еллыгына бик күп

чаралар үткәрелде, шуларның берсе ”декоратив гамәли сәнгать” номинациясе иде. Мин, бу номинациядә катнаштым һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган 30 татар әдибенең исем-фамилиясен, туган-үлгән елларын канвага хач чигүе белән чиктем. Минем хезмәтем татар теле һәм әдәбияты кабинетында эленеп тора.

Арый белмим һич кенә,

Булсын миңа эш кенә.

Эшем бетсә, эш табам:

Кулыма чигү алам.

Бәйгеләрдә дә җиңәм,

Җырларга да өлгерәм.

Укуда да алдынгы мин –

Мәктәпкә очып киләм.